# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Зур Кукмара авылы территориясенең бер өлешендә 2022 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

**2022 елның 05 май** **№ 19**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2022 елда Татарстан Республикасы Кукмара районы Зур Кукмара авылы территориясенең бер өлешендә гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2022 елның 11 маендагы 12 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәреш кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлтергә:

- Зур Кукмара авылының Яшьләр урамын асфальтлау, экспертиза ясау, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру,
- Зур Кукмара авылы Яшьләр урамында юлга вак таш җәю, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.

3. Әлеге карарны Зур Кукмара авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, шулай ук «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә урнаштырырга.

Кукмара муниципаль районы
Зур Кукмара авыл җирлеге башлыгы........................................ Р.Р. Хәнәфиев.